Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге Чертово торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

30 ноябрь, 2021 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлегенең Чертово торак пунктында 2021 елның 30 ноябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 31 (утыз бер).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 17 (унҗиде).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 17 (унҗиде).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез 2022 елда Чертово торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 1 төркем инвалидларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәр балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау»

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Белкино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Белкино авыл җирлеге башлыгы А.Н. Меньшов